**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 июль № 507

г. Казань

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Федоровский картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең профилен үзгәртү турында

Дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 102 койка-урынлы «Федоровский картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең профилен һәм исемен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 110 койка-урынлы «Федоровский картлар һәм инвалидлар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә үзгәртү турындагы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Федоровский картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең профилен үзгәртү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Федоровский картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе уставына үзгәрешләр кертергә;

«Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны административ күзәтү турында» 2011 ел, 6 апрель, ФЗ-64 нче Федераль закон нигезендә административ күзәтү билгеләнгән гражданнарны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Федоровский картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесеннән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мамадыш картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә күчерүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Федоровский картлар һәм инвалидлар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча тиешле финанс елына һәм план чорына күздә тотылган акча чикләрендә, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Уставка үзгәрешләр кертелгәннән соң, бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 804 нче карарына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\507.docx